**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегенең торак пунктында
гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

**03 ноябрь 2023 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2023 елның 03 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләреннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә ризамы:

- Акбаш торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру (шартнамә буенча эшләр өчен түләү).
- Акбаш торак пунктында юллардагы чокырлы ямау;
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Акбаш авыл җирлеге” Акбаш авылы территориясендә җирлек юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 290 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 154 кеше, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 154 катнашучысы тавыш бирә; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.

Язылганнардан чыгып, гражданнар җыены **карар бирә**:

1. Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» Акбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләреннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә ризамы:

- Акбаш торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру (шартнамә буенча эшләр өчен түләү).
- Акбаш торак пунктында юллардагы чокырлы ямау;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Акбаш авыл җирлеге” Акбаш авылы территориясендә җирлек юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)” – сорауларын кабул ителгән дип санарга.

3. Акбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ЮМР Акбаш авыл җирлеге җитәкчесе
вазифаларын башкаручы И.Р.Сәхибуллина